КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 июль г.Казань № 659

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 185 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Иҗтимагый оешмалар сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, шулай ук Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру (иҗтимагый оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аларга карата банкротлык процессы билгеләнмәү, иҗтимагый оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булып тормау;

бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.

Иҗтимагый оешмаларның шулай ук социаль әһәмиятле эшчәнлекне гамәлгә ашыру һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен матди-техник һәм кадрлар ресурслары булырга тиеш.»;

2.3 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«иҗтимагый оешманың бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын, шулай ук экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган, иҗтимагый оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазен;»;

3.4 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидия алучылар белән  (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр

катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирелгәндә);»;

уникенче абзацта «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга;

егерменче абзацта «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

5.3 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

5.5 пунктта «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга.

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы бишенче, егерменче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.3 пунктындагы уникенче абзацының гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин